СОВЕТ КАМАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423643 село Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 Камай авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел.(885549)3-55-33 ИНН 1627001164, КПП162701001 ОГРН 1021601118043

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 3 нче августыннан № 167

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге»нең җирдән файдалану һәм төзелеш объектлары Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131 - ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Уставының 19 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2018ел ның 28 нче августыннан 87 номерлы карары белән раслаган “Татарстан Республикасы Менделеевск районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә”, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2016 ел ның 26 нче августыннан № 29 номерлы карары белән раслаган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш объектлары Кагыйдәләре” нигезендә , Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы Боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре Классификаторына туры китерү максатларындаТатарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2016 ел ның 26 нче августыннан № 29 номерлы карары белән раслаган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш объектлары Кагыйдәләре”нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 3 өлешнең II бүлегендәге 35 статьясында «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

« Күчемсез милекнең рөхсәт ителгән төп төрләре:
- шәхси торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт яны җир кишәрлеге);
- участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары;
- балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы Карары проектын карау буенча ачык тыңлауларны 24.08.2020 елның 24 августында 18 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Камай авыл җирлеге, Камай авылы, Дифгать Сирая урамы, 29б, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең КФҮ.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Камай авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" гы карары проекты белән танышу чорында әлеге проектның демонстратив материаллары экспозициясен оештырырга, кызыксынган затларның искәрмәләре һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Камай авыл җирлеге, Камай авылы, ул. Дифгать Сирая, 29б йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең күпфункцияле үзәге;

5. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ рәсми сайтында Камай авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

Камай авыл җирлеге Советы рәисе И.И.Әһлиева

Кушымта
Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Камай авыл
җирлеге Советының 2020 елның
3 августыннан 167 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында " карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча
комиссия составы

1. Рәисе: Әһлиева Инзилә Ильяс кызы -Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;

2. Рәис урынбасары: Кәлимуллин Рәмис Рафис улы - Камай авыл җирлеге Советы депутаты;

3. Секретарь: Зиннәтуллина Гүзәлия Мөнир кызы-Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;

4. Комиссия әгъзасы: Иванова Айгөл Шамил кызы-Камай төп гомуми белем бирү мәктәбе директоры»;

5. Комиссия әгъзасы: Аннаморадова Римма Борисовна-Камай авыл җирлеге Советы депутаты;

6. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы» инвестицион һәм инфраструктура үсеше идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.